ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә “муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәмен күрсәтергә” сүзләрен “, муниципаль мәгариф оешмаларында һәм балалар өчен өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итүне дә кертеп, балаларга өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә” сүзләренә алмаштырырга;

2) 23 статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Стипендия фондына Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетлары акчалары исәбеннән түләнә торган стипендияләр түләү акчалары керә.”;

б) 6 өлештә “һәм белем алучыларның категорияләре буенча билгеләнгән нормативлардан чыгып” сүзләрен “федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фонды булдыру кагыйдәләре һәм белем алучыларның категорияләре буенча билгеләнгән нормативлар нигезендә” сүзләренә, “булдыру өчен нормативларны” сүзләрен “булдыру өчен нормативларны һәм кагыйдәләрне” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 17 ноябре
№ 84-ТРЗ